Р.З.Хайдарова, Н.Г. Галиева

# ТАТАР ТЕЛЕ

## Укытучылар өчен методик кулланма



4

«Татармультфильм»

УДК 81.432.3-99(=411.2)я72
ББК 811.512.145(073.5)
Х18

Фәнни редакторы
**Р. З. Хәйдәрова**

*Охраняется действующим законодательством об авторских и смежных правах (Гражданский кодекс РФ, ч. 4, гл. 70). Воспроизведение всего издания или его части на любых видах носителей запрещается без письменного разрешения издательства.*

**Хайдарова, Р. З. и др.**
Х18 Государственный (татарский) язык Республики Татарстан: Татар теле. 4 класс: книга для учителя к учебнику для общеобразовательных организаций начального общего образования (для обучающихся, не владеющих татарским языком)/ Р. З. Хайдарова, Н. Г. Галиева. — Казан: Татармультфильм, 2024. – 36 с.

ISBN 978-5-906508-50-8

УДК 81.432.3-99(=411.2)я72
ББК 811.512.145(073.5)

ISBN 978-5-906508-50-8 © «Татармультфильм» нәшрияты, 2024

Р. З. Хәйдәрова, Н. Г. Галиева

# ТАТАР ТЕЛЕ

## 4 нче сыйныф

**Укытучылар өчен методик кулланма**

*Татарстан Республикасы*
*Мәгариф һәм фән министрлыгы*
*тарафыннан тәкъдим ителә*

Казан
2024

## 4 нче сыйныфта «Татар теле» укыту-методик комплекты белән эшләү үзенчәлекләре

Федераль дәүләт башлангыч белем бирү стандартында күрсәтелгәнчә, төп белем бирүнең башлангыч этабы гомуми белем бирүнең нигезе һәм, балаларда белем һәм күнекмәләр булдыру белән беррәттән, аларның уку эшчәнлеген формалаштыруга да нигез сала, гомуми уку күнекмәләрен үстерүне төп максатлар рәтенә куя. Татар теле, танып белү чарасы буларак, укучыларның фикер йөртү, интеллектуаль һәм иҗади сәләтләрен үстерүгә хезмәт итә.

**Укыту-методик комплекты (УМК) аша татар телен дәүләт теле буларак өйрәнү түбәндәге максатларны күзаллый:**

— башлангыч мәктәп укучысының аралашу даирәсен, аралашу ситуацияләрен исәпкә алып, сөйләм эшчәнлегенең барлык төрләре (тыңлап аңлау, сөйләү, уку, язу) буенча укучыларда **коммуникатив компетенция (аралашу осталыгы)** формалаштыру;

— укучының танып белү мөмкинлекләрен, гомуми уку күнекмәләрен, сөйләм культурасын үстерү;

— укучыларның күпмилләтле җирлектә аралашу культурасын формалаштыру, татар халкының мәдәниятенә, милли үзенчәлекләренә карата хөрмәт хисе, мәдәниара диалогка осталык кебек универсаль шәхси күнекмәләр формалаштыру;

— укучыларны рухи һәм әхлакый яктан тәрбияләү;

— укучыларның фикер йөртү, интеллектуаль һәм иҗади сәләтләрен үстерү.

4 нче сыйныфта укучы рус телле балаларга тәкъдим ителгән укыту-методик комплекты түбәндәге компонентлардан тора:

1. Дәреслек.
2. Дәреслекнең электрон формасы.
3. Укытучы өчен методик ярдәмлек:
   - ишетеп аңлау күнегүләре;
   - федераль эш программасына нигезләнгән календарь-тематик план;
   - контроль-үлчәм материаллары.

УМКга эчтәлек сайлау Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының 18.05.2023 елгы 372 нче санлы «Башлангыч гомуми белем

бирүнең федераль эш программасын раслау турында»гы хатына (теркәлү вакыты: 12.07.2023 ел, №74229) һәм тел өйрәтү процессында методик стандарт итеп кабул ителгән коммуникатив технология принципларына нигезләнде.

Дәреслеккә түбәндәге аралашу темалары кертелде: «Яңа уку елы котлы булсын!», «Минем туган илем», «Туган як табигате», «Хайваннар һәм кошлар дөньясында», «Сәламәтлек — зур байлык», «Минем дусларым», «Безнең шөгыльләр», «Минем бер көнем», «Без сәяхәт итәбез».

Дәреслектә түбәндәге грамматик материал урын алды:

— исемнәрнең килеш белән төрләнеше;

— сыйфатның артыклык дәрәҗәсе;

— микъдар һәм тәртип саннары (1-1000);

— *иртән, кичен, кышын, җәен, язын, көзен, аннан соң* вакыт рәвешләре;

— хәзерге һәм билгеле үткән заман хикәя фигыльләрнең I, II, III зат берлек һәм күплек саннарда барлык һәм юклык формалары;

— билгесез үткән заман хикәя фигыльнең III зат берлек сандагы барлык формасы;

— *турында* бәйлегенең исемнәр һәм зат алмашлыклары белән кулланылышы;

— *да, дә; та, тә; иң, бик* кисәкчәләре;

— *чөнки* теркәгече;

— *шуңа күрә* мөнәсәбәтле сүзе.

4 нче сыйныфта укыту процессын оештыру үзенчәлеге шунда: нигездә, алдагы сыйныфларда таныш булган аралашу сфераларында сөйләшә алу мөмкинлекләре тирәнәйтелә.

Методик ярдәмлектә **аудирование** (ишетеп аңлау күнегүләре*)*, укучыларның белемен контрольгә алу өчен биремнәр тәкъдим ителә. Ишетеп аңлау күнегүләре һәр дәрестә, дәреснең төрле этапларында кулланыла ала. Ишетеп аңлау күнегүләренә таләпләр кечерәк сыйныфлар өчен чыгарылган ярдәмлекләрдә киң яктыртылу сәбәпле, күнегүләрнең үзләрен бирү белән генә чикләндек.

Укыту процессының уңышлылыгына тәэсир итә торган әһәмиятле факторларның берсе — ул укучыларның белемен **контрольгә** алу. Билгеле булганча, **контроль** уку-укыту барышын көйли, ягъни, контрольгә карап, укытучы үз эшчәнлеген оештыра. Методика фәне билгеләгәнчә, укучыларның аерым сүзләрне, җөмләләрне тәрҗемә итә белүләре, яисә

грамматик категорияләрне аңлый алулары гына **контроль объекты** була алмый. Контрольнең төп объекты — укучының өйрәнелгән лексиканы һәм грамматиканы кулланып, **мөстәкыйль аралаша алуы**.

Тәкъдим ителгән тематик план **программа** материалның ел дәвамында дәресләргә бүленешен күрсәтә. Календарь-тематик планның коммуникатив максат графасында күрсәтелгән предмет нәтиҗәләре балаларның белем дәрәҗәсенең, ягъни татарча сөйләшеп аралаша алуының күрсәткече булып тора, шуңа күрә дәрес планын, дәреснең структур этапларын планлаштырганда, аңа игътибар итү аеруча мөһим.

## Ишетеп аңлау күнегүләре

## Яңа уку елы котлы булсын!

### 1–4 нче дәресләр

**1. Прослушайте и укажите слова со звуком [ә].**
Белем, бәйрәм, мәктәп, шат, чәчәк, кәеф, яхшы.

**2. Прослушайте и укажите слова со звуком [ә̆].**
Дәфтәр, белем, каләм, бетергеч, килешә, матур.

**3. Прослушайте и укажите двусложные слова.**
Яңа, уку елы, башланды, кәеф, яңа, кирәк, түгел.

**4. Прослушайте и повторите эти слова, добавляя к каждому из них вопросительную частицу *-мы/-ме.* Составьте вопросительные предложения.**
Китап, чәчәк, дәфтәр, дәрес, дәреслек, сүз, сүзлек.

**5. Прослушайте и укажите, что добавлено во втором предложении каждой пары.**

1) Син бүген матур. Син бүген бик матур.
2) Мин сине котлыйм. Мин сине бәйрәм белән котлыйм.
3) Мин шат. Мин дә шат.

**6. Прослушайте и укажите, что изменено во втором предложении каждой пары.**

1) Сумкада китап бар. Сумкада 3 китап бар.
2) Сумкада бетергеч бар. Минем сумкада бетергеч бар.
3) Синең портфельдә ничә китап бар? Синең портфельдә ничә дәфтәр бар?

## 5–7 нче дәресләр

**1. Прослушайте и повторите эти слова, добавляя к каждому из них местоимение *минем (синең, аның).***

Китап, чәчәк, дәфтәр, дәрес, дәреслек, сүз, сүзлек.

**2. Прослушайте и укажите, что добавлено во втором предложении каждой пары.**

1) Мин сине котлыйм. Мин сине бәйрәм белән котлыйм.
2) Миңа дәфтәр кирәк. Миңа шакмаклы дәфтәр кирәк.

**3. Прослушайте и укажите, что изменено во втором предложении каждой пары.**

1) Син нәрсә алдың? Син нәрсә алмадың?
2) Мин яңа сумка алдым. Мин яңа көндәлек алдым.

## 8–9 нчы дәресләр

**1. Прослушайте и укажите слово со звуком [қ].**

Кош, кара, күз, карга, агач, оя, кыр, бәйрәм, мәктәп.

**2. Прослушайте и повторите эти слова, добавляя к каждому из них метоимение *минем*.**

Китап, эш, чәчәк.

**3. Прослушайте и выделите слова с кратким произношением звука [ŏ].**

Алты, йокы, солдат, йорт, почта, орлык, озын, болын.

**4. Прослушайте и укажите, какой звук слышится и какая буква пишется во втором слоге слова.**

Сөлге, болыт, озын, төлке, болын, олы, көчле, орлык, солы, йокы.

**5. Назовите слово, лишнее в логическом ряду.**

Озын, олы, кош, орлык, эт, болын.

## 10–11 нче дәресләр

**1. Прослушайте и расположите числа по порядку.**

Бер, сигез, ун, ике, биш, өч, җиде, дүрт, алты, тугыз.

**2. Назовите слово, лишнее в логическом ряду.**

Беренче, икенче, өченче, дүртенче, биш, бишенче, алтынчы, җиденче, сигезенче.

**3. Прослушайте и скажите, какие числа пропущены?**

10, 20, 30, 50, 60, 70, 80, 100.

**4. Прослушайте диалог и расскажите об Айбулате.**

— Айбулат, сиңа ничә яшь?
— Ун яшь.
— Син ничәнче сыйныфта укыйсың?
— Дүртенче сыйныфта укыйм.
— Ә ничәнче мәктәптә?
— 22 нче мәктәптә.

**5. Прослушайте и назовите вопросительные предложения.**

1) Миңа музыка дәресе ошый. 2) Бер атнада ничә көн? 3) Син быел дүртенче ел татар теле өйрәнәсең. 4) Синең сумкада нәрсә бар?

## 12–14 нче дәресләр

**1. Прослушайте и укажите слова со звуком [ч].**

Һәрвакыт, чиста өстәл, китап, кәгазь, чөнки, дүртенче, каләм, чәчәк.

**2. Прослушайте и повторите эти слова, добавляя к каждому из них местоимение *синең*.**

Көндәлек, өстәл, компьютер, каләм, бетергеч, китап, сумка.

**3. Прослушайте и измените предложения по образцу.**

*Образец:* Оляга китап кирәк. — Оляга китап кирәк түгел.

Кызга каләм кирәк. Безгә өстәл кирәк. Миңа чәчәк кирәк. Аңа плеер кирәк.

**4. Прослушайте и скажите, что добавлено во втором предложении каждой пары.**

Алсу тәртип ярата. Алсу тәртип, чисталык ярата.

Айдарның эш урыны чиста. Айдарның эш урыны һәрвакыт чиста.

**5. Прослушайте и укажите словосочетания, в которых есть слова, отвечающие на вопрос *нинди?***

Тәртипсез малай, тәрбияле бала, мәктәпкә бара, игътибарлы укучы, кирәкле китап, чисталык ярата, эшчән кеше.

## 15–16 нчы дәресләр

**1. Прослушайте и укажите слова со звуком [ү].**

Күнегү, мисал, дөрес, күңелле, яза, җавап, үзе, мәсьәлә, җавап.

**2. Прослушайте и определите количество слогов в каждом слове.**

Диктант, без, җавап, бүген, дөрес, эш, кызык, кич, кичә, ярамый.

**3. Назовите слова, выражающие действия.**

Чиште, яза, укый, хикәя, сөйләми, күчермәде, иптәш, кәеф, күчерде.

**4. Назовите слово, лишнее в логическом ряду.**

Мәсьәлә, диктант, мисал, дөрес, контроль эш.

**5 Прослушайте и измените предложения по образцу.**

*Образец:* Марат мәктәптән кайтты. Марат мәктәптән кайтмады.

Бүген рус теленнән контроль эш булды.

Мин мәсьәләне дөрес чиштем.

Гүзәл мисалны дөрес эшләде.

Кичә бик күңелле булды.

## 17–23 нче дәресләр

**1. Прослушайте и укажите слова, в которых есть звук [ә].**

Дәрестә, сөйли, кәеф, мәсьәлә, эшчән, сүз, кирәк, мисал, яза, күңелле.

**2. Прослушайте и измените по образцу.**
*Образец:* дөрес чиштем — дөрес чишмәдем.
Мәсьәләне дөрес чиштем; мисалны дөрес эшләдем; телевизор карадым.

**3. Прослушайте и укажите слова, отвечающие на вопрос *нинди?***
Тырыш, көлә, кирәк, әдәпле, ялкау, хикәя, игътибарлы, эшли.

**4. Прослушайте и измените предложения по образцу.**
*Образец:* Мин өй эшен әзерләдем — Миңа өй эшен әзерләмәдем.
Мин мисал эшләдем.
Мин мәсьәлә чиштем.
Айдар мәктәпкә барды.
Миңа дуслар килде.

**5. Прослушайте и укажите словосочетания, в которых есть слова, отвечающие на вопрос *нинди?***
Тәртипсез кыз, тәрбияле бала, мәктәпкә бара, игътибарлы укучы, кирәкле китап, чисталык ярата, эшчән кеше, ялкау кыз.

## Минем туган илем

### 24–27 нче дәресләр

**1. Прослушайте и укажите слова со звуком [ғ].**
Туган як, киң, кыр, озын, елга, Бөгелмә, Агыйдел, Алабуга.

**2. Прослушайте и укажите двусложные слова.**
Кыр, күл, төлке, усал, бүре, зур, озын, аю, як.

**3. Прослушайте и укажите лишнее слово в логическом ряду.**
Агыйдел, Кама, Чистай, Идел.

**4. Прослушайте и составьте предложения.**
*Образец:* Татарстан. — Мин Татарстанда яшим.
Чаллы. Түбән Кама. Казан. Шәһәр. Авыл.

**5. Прослушайте и воспроизведите диалог.**
— Сәлам!
— Сәлам!
— Мин Маша.
— Ә минем исемем Алия.
— Син кайда яшисең?
— Мин Чаллыда яшим, ә син кайда яшисең?
— Казанда яшим.

**6. Прослушайте и, если не согласны, дайте отрицательный ответ.**
1) Россия — зур, бай дәүләт. 2) Россиядә шәһәрләр бик аз. 3) Россиянең табигате бик матур. 4) Мәскәү — кечкенә шәһәр.

## 28–29 нчы дәресләр

**1. Прослушайте и укажите слово, лишнее в логическом ряду.**
Лена, Идел, Енисей, Яр Чаллы, Агыйдел.

**2. Прослушайте и укажите, что изменено во втором предложении каждой пары.**
1) Мәскәү — тарихи шәһәр. Мәскәү — борынгы шәһәр.
2) Флагта ак, кызыл, зәңгәр төсләр бар. Флагта зәңгәр, яшел, ак төсләр бар.
3) Татарстан гербында барс сурәтләнгән. Татарстан гербында канатлы барс сурәтләнгән.

**3. Прослушайте и повторите, добавляя к словам местоимения минем, синең, аның.**
Туган ил, милләт, республика, шәһәр, авыл.

## 30–32 нче дәресләр

**1. Прослушайте и укажите слова со звуком [ә].**
Дәүләт, татар, башкорт, милләт, телләр, белоруслар, дус, яшиләр, өйрәнә, белә.

**2. Прослушайте диалог и расскажите содержание.**

— Тимур, син кайда яшисең?
— Мин Казанда яшим.
— Син нинди милләттән?
— Мин — рус. Айваз, син нинди милләттән?
— Мин — татар.

### 33–37 нче дәресләр

**1. Прослушайте и укажите слово со звуком [ө].**

Казан, шәһәр, манара, Сөембикә, дәүләт, музей, мәчет.

**2. Прослушайте и укажите слова, отвечающие на вопрос *кайда?***

Казанда, музейга, манарада, экскурсиягә, шәһәрдә.

**3. Пролушайте и укажите слово, лишнее в логическом ряду.**

Матур, яшь, тарихи, шәһәр, яңа, зур.

**4. Прослушайте и, если не согласны, дайте отрицательный ответ.**

1) Казан — Татарстанның башкаласы. 2) Кол Шәриф мәчете Яр Чаллыда урнашкан. 3) Казанда Сөембикә манарасы бар. 4) Кремль янында музей юк.

## Туган як табигате

### 38–43 нче дәресләр

**1. Прослушайте и укажите слова, в которых есть звук [ŏ].**

Киң, болын, урман, агач, җир, күл, болыт, туган як, озын, табигать, кош, көн, көз.

**2. Прослушайте и укажите слова с мягкими гласными.**

Җир, су, күк, кояш, ай, җәнлекләр, кошлар.

**3. Прослушайте и укажите слова со звуком [ө].**

Яңгыр, һава, көндез, җил, көньяк, төньяк, явымсыз, болыт, кар, эссе, салкын.

**4. Прослушайте и скажите, сколько предложений в тексте.**

Менә көз җитте. Көннәр кыскарды, төннәр озынайды. Кошлар җылы якка киттеләр. Салкын җил исә.

**5. Прослушайте и укажите слова, отвечающие на вопрос *нишли?***

Салкын, туңа, кыздыра, кыр, китә, ява, җылынды.

**6. Прослушайте и укажите слова, отвечающие на вопрос *нишләде?***

Менә көз җитте. Көннәр кыскарды, төннәр озынайды. Кошлар җылы якка киттеләр. Салкын җил исә.

**7. Прослушайте и укажите словосочетания, в которых есть слова, отвечающие на вопрос *нинди?***

Эссе көн, һава торышы, салкын җил, кар ява, озын көн, агач яфраклары, көз җитә, кыска көн, сары яфрак.

**8. Прослушайте и добавьте к каждому существительному соответствующее прилагательное.**

Урман, җил, яфрак, уңыш, яңгыр.

**9. Прослушайте диалог и расскажите о приметах осени.**

— Син нинди көз билгеләрен беләсең?
— Көннәр кыскара, төннәр озыная.
— Кошлар кая китәләр?
— Кошлар җылы якка китәләр.
— Көз көне һава торышы нинди?
— Җил исә, салкын яңгырлар ява.

**44–49 нчы дәресләр**

**1. Прослушайте и укажите слова со звуком [ө].**

Поши, тиен, җәнлек, бүре, төлке, кабан дуңгызы.

**2. Прослушайте и укажите слова со звуком [ү].**

Дару, туган як, мәтрүшкә, урман, болын, киң, үлән, искиткич, сәламәтлек.

**3. Прослушайте и назовите слова, выражающие действия.**

Зур, ага, яши, күп, бар, матур, бара, җыя.

**4. Прослушайте диалог и расскажите содержание.**

— Сезнең туган якта урманнар бармы?
— Зур урманнар да, киң болыннар да бар.
— Ә нинди агачлар үсә?
— Нарат, каен, имән, чыршы, юкә агачлары үсә ?
— Ә дару үләннәре бармы?
— Гөлҗимеш, мәтрүшкә, ромашка бик күп.

**5. Прослушайте и укажите, что изменено во втором предложении каждой пары.**

1) Бу помидор кызыл. Бу помидор кызылрак.
Бу кыяр зур. Бу кыяр зуррак.
Бу күлмәк зәңгәр. Бу күлмәк зәңгәррәк.
Бу чәчәк матур. Бу чәчәк бик матур.
Бу яулык ак. Бу яулык ап-ак.

2) Флагта ак, кызыл, зәңгәр төсләр бар. Флагта зәңгәр, яшел, ак төсләр бар.

3) Татарстан гербында барс сурәтләнгән. Татарстан гербында канатлы барс сурәтләнгән.

## 50–51 нче дәресләр

**1. Прослушайте и укажите слова, отвечающие на вопрос *нишләде?***

Менә көз җитте. Көннәр кыскарды, төннәр озынайды. Кошлар җылы якка киттеләр. Салкын җил исә.

**2. Прослушайте и укажите, что изменено во втором предложении каждой пары.**

1) Бу күбәләк зур. Бу күбәләк зуррак.
2) Бу агач биек. Бу агач биегрәк.
3) Бу чәчәк сары. Бу чәчәк сап-сары.

**3. Прослушайте и назовите слова, выражающие действие.**

Бай, файдалы, дәвалый, ныгыта, ашказаны, белә, үсә, дару.

**4. Назовите слово, лишнее в логическом ряду.**

Бака яфрагы, гөлҗимеш, кузгалак, мәтрүшкә, файдалы, кычыткан.

## Хайваннар һәм кошлар дөньясында

### 52–53 нче дәресләр

**1. Прослушайте и укажите слова со звуками [ҕ].**
Карлыгач, сандугач, чыпчык, карга, песнәк.

**2. Прослушайте и укажите слова со звуком [ү].**
Аккош, күгәрчен, торна, күке, кыр казы.

**3. Прослушайте и назовите слова, выражающие действия.**
Зур, ага, яши, күп, бар, матур, бара, җыя.

**4. Прослушайте диалог и дополните.**
— Сезнең туган якта нинди кошлар бар?
— ... .
— Ә нинди кошлар җылы якларга китә?
— ...

**5. Прослушайте и укажите, что изменено во втором предложении каждой пары.**
1) Бу кош зур. Бу кош зуррак.
2) Бу кош кечкенә. Бу кош кечкенәрәк.
3) Бу кош матур. Бу кош бик матур.

### 54–58 нче дәресләр

**1. Прослушайте и укажите слова со звуком [ы̆].**
Песнәк, чукый, ашый, Әнисә, шатланды, тәрәзә, ачты, канат, салкын.

**2. Прослушайте и определите количество слогов в каждом слове.**
Песнәк, ашый, Әнисә, шатланды, тәрәзә, ачты, канат какты, салкын.

**3. Назовите слова, выражающие действия.**
Песнәк, ашады, Әнисә, шатланды, тәрәзә, ачты, канат какты, салкын, рәхмәт әйтте.

**4. Назовите слово, лишнее в логическом ряду.**
Ашады, шатланды, ачты, канат какты, салкын, рәхмәт әйтте, чукыды.

**5. Прослушайте и скажите, что изменено во втором предложении каждой пары.**

1) Көн салкын иде. Көн салкын түгел иде.
2) Песнәк тәрәзә шакый. Песнәк тәрәзә шакымый.
3) Әнисә песнәккә май бирде. Әнисә песнәккә май бирмәде.
4) Песнәк Әнисәгә ияләште. Песнәк Әнисәне яратты.

## 59–60 нчы дәресләр

**1. Прослушайте и укажите слова со звуком [җ].**

Урындык, кыш көне, җимлек, салкын, җил, куйды.

**2. Прослушайте и укажите двусложные слова.**

Агач, кыш көне, җимлек, рәхмәт, ясады, җил, куйды.

**3. Прослушайте и укажите, что изменено во втором предложении каждой пары.**

1) Кичә Дима җимлек ясады. Кичә Дима җимлек ясамады. `
2) Ул кошларга җимлек куйды. Ул кошларга җимлек куймады.
3) Кошлар Димага рәхмәт әйттеләр. Кошлар бик сөенделәр.

## 61–62 нче дәресләр

**1. Прослушайте и укажите слова со звуком [ө].**

Арыслан, фил, куян, бүре, дөя, аю, тиен, ташбака, керпе, төлке.

**2. Прослушайте и переведите слова.**

Соры, ак, кара, озын колаклы, озын койрыклы, хәйләкәр, усал, ит бирә, сөт бирә, йон бирә, тиз йөгерә, зур.

**3. Прослушайте и укажите двусложные слова.**

Соры, ак, кара, озын колаклы, озын койрыклы, хәйләкәр, усал, ит бирә, сөт бирә, йон бирә, тиз йөгерә, зур.

**4. Прослушайте и укажите слова, отвечающие на вопросы *нинди?* и *ничек?***

1) Ак куян зур, соры куян зуррак. 2) Төлке усал, ә бүре усалрак. 3) Аю әкрен йөгерә, бүре тиз йөгерә, ә куян бик тиз йөгерә.

### 63–64 нче дәресләр

**1. Прослушайте и укажите слова со звуками [ч, ң].**

Көн, салкын, җил, туңа, йомшак, өй, ап-ак, чаңгы, буран, чана, боз, тун, чыршы.

**2. Прослушайте и укажите двусложные слова.**

Салкын, елга, боз, каплый, буран, су, туңа, кар.

**3. Прослушайте и повторите эти слова, добавляя к каждому из них местоимение *синең*.**

Борын, баш, күз, кул, чаңгы.

## Сәламәтлек — зур байлык

### 65–66 нчы дәресләр

**1. Прослушайте и укажите слова со звуком [к].**

Ирен, колак, күз, авыз, аяк, борын, кирәк, аптека.

**2. Прослушайте и укажите двусложные слова.**

Баш, борын, чәч, күз, колак, ирен, кул.

**3. Прослушайте и повторите эти слова, добавляя к каждому из них местоимения *минем (синең, аның)*.**

Кул, аяк, күз, баш, аяк, эч, арка.

**4. Прослушайте и скажите, сколько предложений в тексте.**

Минем башым авырта. Тамагым авыртмый. Миңа дару кирәк. Мин аптекага барам.

**5. Прослушайте и скажите, что добавлено во втором предложении каждой пары.**

1) Гүзәлнең башы авырта. Гүзәлнең теше, башы авырта.

2) Гүзәл мәктәпкә бармады. Бүген Гүзәл мәктәпкә бармады, чөнки ул авырый.

## 67–71 нче дәресләр

**1. Прослушайте слова и добавьте к каждому из них местоимения *минем, синең*.**

Чаңгы, чана, велосипед, туп, тимераяк.

**2. Прослушайте и измените предложения по образцу.**

*Образец:* Мин велосипедта йөрим.— Син дә йөрисеңме ?

1) Мин шахмат уйныйм. —
2) Мин шашка уйныйм. —
3) Мин футбол уйныйм. —
4) Мин баскетбол уйныйм. —
5) Мин теннис уйныйм. —

**3. Прослушайте и укажите вопросительные предложения.**

Коля тауга бара. Син тауга барасыңмы? Минем чанам бар. Синең чанаң бармы? Мин чана шуам. Син чана шуасыңмы?

**4. Прослушайте и закончите предложения.**

Нәсим тауга ... . Нәсим тауда ... . Нәсим таудан ... .

**5. Прослушайте и укажите, что изменено во втором предложении каждой пары.**

1) Балалар тауда чаңгы шуалар. Балалар тауда чаңгы шудылар.
2) Балалар тауда тимераякта шуалар. Балалар тауда тимераякта шудылар.
3) Минем тимераякларым юк. Минем чаңгым, тимераякларым юк.
4) Миңа тимераяклар кирәкми. Миңа тимераяклар алмадылар.
5) Миңа тимераяклар кирәк. Миңа тимераяклар алдылар.

**6. Прослушайте вопросы и ответьте на них положительно.**

1) Чаңгы ярышы буламы?
2) Син чаңгы ярышына барасыңмы?
3) Син чаңгы ярышына бардыңмы?
4) Син беренче урын алдыңмы?

**7. Прослушайте и расскажите содержание текста.**

Игорь белән Федя — дуслар. Җәй көне бергә футбол уйныйлар, кыш көне чаңгы шуалар. Алар икесе дә бик яхшы шуалар.

**72–75 нче дәресләр**

**1. Прослушайте и укажите слова со звуком [ә].**

Язучы, әкият, хикәя, повесть, шигырь, шагыйрь, мәзәк.

**2. Прослушайте и укажите слово, лишнее в логическом ряду.**

Шигырь, әкият, язучы, хикәя, повесть, мәзәкләр.

**3. Прослушайте и укажите слово, лишнее в логическом ряду.**

Алып кайткан, кигән, салды, авырткан, барган, йөгергән, тыңламаган.

**4. Прослушайте и укажите, что изменено в каждом последующем предложении.**

1) Куянның матур кызы булган.
Соры куянның матур кызы булган.
Соры куянның бер матур, иркә кызы булган.

2) Әнисе яңа итекләр алып кайткан.
Әнисе Куян кызына яңа итекләр алып кайткан.
Бервакыт әнисе Куян кызына яңа итекләр алып кайткан.

**5. Прослушайте и расскажите содержание текста.**

Бер соры Куянның бик иркә, бик кадерле бер кызы булган. Ул аны бик яраткан. Бервакыт Куян кызына яңа киез итекләр алып кайткан.

— Мә, кызым, аякларың туңмасын, авыртмасын, — дигән. Кыз бик шатланган. Әнисенә рәхмәт әйткән.

**76–79 нчы дәресләр**

**1. Прослушайте и укажите слова со звуком [ы].**

Тимераяк, башым, көлә, кыз, үзе, тыңламый, камыраяк.

**2. Прослушайте и укажите слово, лишнее в логическом ряду.**

Тимераяк, чана, боз, чаңгы.

**3. Прослушайте и укажите, что изменено во втором предложении каждой пары.**

1) Азат тимераякта шуа белә. Азат чаңгыда шуа белә.
2) Азат бозда егыла. Азат тауда егыла.
3) Азат тауда чаңгы шуа. Азат урманда чаңгы шуа.

**4. Прослушайте и дополните предложения.**

1) Азат шугалакка ... .
2) Азат шугалакта ... .
3) Азат шугалактан ... .

## Минем дусларым

### 80–86 нчы дәресләр

**1. Прослушайте и повторите эти слова, добавляя к каждому из них местоимения *минем, синең, аның*.**

Дус, авыл, шәһәр.

**2. Прослушайте и укажите слово, лишнее в логическом ряду.**

Авыл, шәһәр, дус, җәй, дуслаштык, әби, йорт.

**3. Прослушайте и укажите слова, отвечающие на вопрос *кайда?***

Авылда, шәһәрдә, мәктәптән, түгәрәккә, өйдә, урамнан.

**4. Прослушайте вопросы и ответьте на них положительно.**

1) Синең дустың бармы?
2) Аның исеме Катямы?
3) Ул шәһәрдә яшиме?
4) Ул яхшы кызмы?

**5. Прослушайте и укажите, что изменено во втором предложении каждой пары.**

1) Без дустым белән авылда таныштык. Без дустым белән шәһәрдә таныштык.
2) Без авылда торабыз. Без шәһәрдә торабыз.

**6. Прослушайте и расскажите содержание текста.**

Бакчачы бабай Чулпанга бер алма бирде. Ул бик матур һәм хуш исле иде. Чулпанның алманы ашыйсы килде. Дәрес әзерләгәндә, Чулпан гел алмага карап утырды. Менә ул түзмәде, дуслары янына мәктәпкә китте. Ул дусларына алмаларны бирде. Аларга бик күңелле булды.

## Безнең шөгыльләр

### 87–91 нче дәресләр

**1. Прослушайте и укажите слова, обозначающие действия.**

Барам, яши, икәү, телим, шигырь, сөйли, түгәрәк, йөри, заманча.

**2. Прослушайте и укажите слова, отвечающие на вопрос *нинди?***

Алсу — оста биюче, яхшы укучы, эшчән кыз.

**3. Прослушайте и укажите, что добавлено во втором предложении каждой пары.**

1) Алсу апа безгә рус, татар биюләре өйрәтә. Алсу апа безгә рус, татар, заманча биюләр өйрәтә.

2) Айгөл әнисенә ашарга пешерергә булыша. Айгөл әнисенә ашарга пешерергә, өй җыештырырга булыша.

3) Без бергә уйныйбыз, дәрес әзерлибез. Без бергә уйныйбыз, дәрес әзерлибез, чаңгы шуабыз.

**4. Прослушайте и скажите антонимы к данным словам.**

Эшчән, яхшы, ялкау, юмарт.

**5. Прослушайте и закончите предложения.**

1) Без бүген бию түгәрәгенә ... . 2) Мин яңа гына бию түгәрәгеннән ... . 3) Без дустым белән бию түгәрәгендә ... .

**6. Прослушайте вопросы и отвечайте на вопросы положительно.**

1) Саша, сиңа нинди түгәрәк ошый? 2) Син анда ничә ел йөрисең? 3) Сез түгәрәктә нишлисез? 4) Оля, син менталь санауга йөрисеңме? 5) Синеңчә, менталь санау ни өчен файдалы?

## Минем бер көнем

### 92–93 нче дәресләр

**1. Прослушайте и переведите.**

Который час? Во сколько часов? Шесть часов. В шесть часов. В половине шестого.

**2. Прослушайте и дополните предложения.**

Сәгать сигездә мәктәптә дәресләр ... . Сәгать бердә мәктәптә ... . Сәгать икедә Алёша көндезге аш ... . Сәгать биштә Алёша дәрес ... . Сәгать унда ул йокларга ... .

**3. Прослушайте и укажите, что изменено во втором предложении каждой пары.**

1) Алёша сәгать җидедә тора. Алёша сәгать җиденче яртыда тора.
2) Алёша салкын су белән юына. Алёша җылы су белән юына.
3) Дәресләр сәгать сигездә башлана. Дәресләр сәгать бердә башлана.
4) Дәресләр сәгать икедә бетә. Дәресләр сәгать бердә бетә.
5) Алёша әнисенә булышмый. Алёша әнисенә булыша.
6) Гаиләдә кичке ашны бергә ашыйлар. Алёша кичке ашны үзе генә ашый.
7) Алёша кичке унбердә йокларга ята. Алёша кичке унда йокларга ята.

### 94–95 нче дәресләр

**1. Прослушайте и укажите слова со звуком [ң].**

Сәгать, даң-даң, таң, Марат, дәрес, соңга калган, йоклаган.

**2. Прослушайте текст и расскажите содержание.**

Марат бүген озак йоклады. Ул сәгать сигезенче яртыда гына торды. Мәктәптә дәресләр сәгать сигездә башлана. Марат дәрескә соңга калды.

**3. Прослушайте вопросы и ответьте на них.**

— Син ничәнче сменада укыйсың?
— Мәктәптән сәгать ничәдә кайтасың?
— Сәгать ничәдә дәрес әзерлисең?

## 96–98 нче дәресләр

**1. Прослушайте укажите слова, в которых есть звуки [йа].**

Авыраяк, озак, йоклый, уяна, яши, тимераяк, пальто, эзли, артында, бүрек, өстәл, бияләй, кия, астында, боз, янында.

**2. Прослушайте и укажите слова, которые отвечают на вопрос *кайда?***

Өстәлдә, авылда, урамда, боз, озак, каршында, астында, өстә, тиз, алдында, торды.

**3. Прослушайте и повторите эти слова, добавляя к каждому из них местоимение *минем (синең, аның).***

Бүрек, бияләй, тимераяк.

**4. Прослушайте и укажите слова, отвечающие на вопрос *ничек?***

Тиз, боз, каткан, озак, авыр, җиңел, алдында, артында.

**5. Прослушайте и, если не согласны, дайте отрицательный ответ.**

Авыраяк иртә торды. Авыраякның бүреге элгечтә иде. Авыраяк тимераякны киде дә тиз генә урамга чыкты.

**6. Прослушайте и укажите, что изменено во втором предложении каждой пары.**

1) Пальтоны эзләделәр. Пальтоны бик озак эзләделәр.
2) Бүрек өстәл артында иде. Бүрек өстәл янында иде.
3) Бияләйләр карават астында иде. Бияләйләр карават янында иде.

**7. Прослушайте и, если не согласны, дайте отрицательный ответ.**

1) Авыраяк иртә торды.
2) Авыраяк тимераякларны үзе тапты.
3) Авыраяк үзе киенде.
4) Авыраяк урамга бик тиз чыкты.

## Без сәяхәт итәбез

### 99–102 нче дәресләр

**1. Прослушайте укажите слова, в которых есть звуки [йә].**
Сәяхәт, тарихи, ял, кая, борыңгы, ярдәмчел, җәяү, диңгез, ярата, шәһәр .

**2. Прослушайте и укажите слово, лишнее в логическом ряду.**
Владимир, Иваново, Кострома, Ростов, шәһәр, Сергиев Посад, Суздаль.

**3. Прослушайте и укажите, что изменено во втором предложении каждой пары.**

1) Болгар — тарихи шәһәр. Болгар — борынгы шәһәр.
2) Мин җәй көне диңгезгә бардым. Мин җәй көне Казанга бардым.
3) Мин сәяхәт итәргә яратам. Мин теплоход белән сәяхәт итәргә яратам.

**4. Прослушайте и повторите, добавляя к словам местоимения *минем, синең, аның.***
Дус, шәһәр, сәяхәт, теплоход, ял.

**5. Прослушайте и укажите слова, отвечающие на вопрос *нинди?***
Урын, тарихи, ял, борынгы, диңгез, күп, зур, хат.

**6. Прослушайте и укажите имена мальчиков.**
Равил, Ваня, Шамил, Сания, Нәсимә, Володя, Рафаэль, Ләйсән, Рәсимә.

## Федераль эш программасына нигезләнгән календарь-тематик план

| № | Дәрес темасы | Дәреснең коммуникатив максаты | Лексика |
|---|---|---|---|
| **Яңа уку елы котлы булсын! (23 сәгать)<br>III Мир вокруг меня** | | | |
| 1–2 | Яңа уку елы белән! | 1 нче сентябрь бәйрәме белән котлый белү;<br>бер-береңә комплиментлар әйтә белү | Белем бәйрәме яңа уку елы,<br>башлана,<br>килешә,<br>сәламәтлек,<br>уңышлар,<br>котлыйбыз |
| 3–4 | Уку — язу әсбаплары.<br>Зат алмашлыкларының юнәлеш килеше формасы.<br>С.Маршакның «Һәр атнада җиде көн» шигыре | Уку-язу әсбапларын үзеңә сорап ала, иптәшеңә тәкъдим итә белү | дәрес,<br>дәреслек,<br>шакмаклы,<br>сызыклы,<br>кирәк,<br>түгел |
| 5–7 | Яңа уку елына әзерлек.<br>«Миңа дәфтәр кирәк» | Яңа уку елына нинди уку-язу әсбапларын алу турында, уку-язу әсбапларының барлыгын, юклыгын әйтә белү | |
| 8–9 | Татар алфавиты | Татар теленең хәреф-аваз системасын сөйли белү | аваз,<br>хәреф |
| 10–11 | Микъдар һәм тәртип саннары (1–1000) | Саннар кулланып, үзең, сыйныфың турында сөйли белү | кушарга, алырга,<br>бүлергә, мисал,<br>мәсьәлә |
| 12–14 | Минем эш урыным.<br>*Чөнки, шуңа күрә* теркәгечләре | Эш урының турында сөйли, дустыңнан өстәлгә нәрсәләр куюың турында сорый белү.<br>*Чөнки, шуңа күрә* теркәгечләре белән фикереңне дәлилли белү | тәртип, һәрвакыт,<br>эш урыны,<br>язу өстәле,<br>куям,<br>тырыш, ялкау,<br>игътибарлы,<br>тәртипле |
| 15–16 | Дәрестә | Дәрестә үзеңнең/ иптәшеңнең нишләгәнең/ нишләгәне турында, ничәле алуың турында әйтә, сорый белү | мисал, мәсьәлә<br>контроль эш җавап,<br>сорау, күнегү,<br>чишә, эшли,<br>хаталы (-сыз)<br>математикадан |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 17–19 | «Алсуның кәефе юк» хикәясе | Нинди дәресләр булуы, мисалны, мәсьәләне дөрес чишүең-чишмәвең, нинди билгеләр алуың турында әйтә, дустыңнан сорый белү | кәеф,<br>кичә, башта,<br>аннан соң |
| 20–21 | Без хикәя язабыз! Хикәя фигыльнең заман формалары | Хикәяне үзгәртеп төзү яисә үз хикәяңне язу | |
| 22–23 | Кабатлау дәресләре | | |
| **Минем туган илем. (14 сәгать)<br>IV Моя Родина** | | | |
| 24–25 | Туган илем — Россия.<br>*Иң, бик* көчәйткеч кисәкчәләре. | Россиянең табигате, шәһәрләре турында сөйли белү | Ватан, туган як, туган ил, бай, дәүләт, кырлар, күлләр, елгалар, башкала |
| 26–27 | «Туган илем — Россия» темасына сөйләшү | Кызыл Мәйдан турында сөйләшү | |
| 28–29 | Россия дәүләте һәм Татарстан Республикасы символлары.<br>*да/дә, та/тә* кисәкчәләре | Россия дәүләте һәм Татарстан Республикасы символларын таный, әйтә белү | бөркет,<br>канатлы барс |
| 30–32 | Туган җирем — Татарстан | Туган илеңнең табигате турында, нинди милләтләр барлыгы, ничек яшәүләре турында сөйли белү | милләт |
| 33–35 | *Турында* бәйлеге. Казан — Татарстанның башкаласы | Казанның истәлекле урыннары турында сөйләшү. | мәчет,<br>манара |
| 36–37 | Кабатлау дәресләре | | |
| **Туган як табигате. (14 сәгать)<br>IV Моя Родина** | | | |
| 38–39 | Нәрсә ул табигать?<br>*Кышын, җәен, көзен, язын* — вакыт рәвешләре | Табигать турында сөйләшү | табигать, ел фасылы, кышын, җәен, көзен, язын, вакыт, көз, туңды, саргая, коела |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 40–41 | Билгеле үткән заман хикәя фигыльнең барлык һәм юклык формалары. Көзге табигать | Көзге табигатьне сурәтли белү. Уенга чакыра белү | яңгыр, көньяк, төньяк, эссе, буран |
| 42–43 | Һава торышы. *Иртән, кичен, төнлә* — вакыт рәвешләре | Һава торышын сорый, әйтә белү | һава торышы, иртән, кичен, төнлә, явымсыз, болытлы |
| 44–45 | Хикәя фигыльнең зат-сан белән төрләнеше. «Дару үләннәре» тексты | Урманга, даруханәгә баруың турында, дару үләннәре кирәклеге, аларны җыю яисә сатып алуың турында әйтә белү | туган як, дару үләне, файдалы, бака яфрагы, мәтрүшкә, кычыткан, үги ана яфрагы, даруханә |
| 46–47 | Мин Татарстанда яшим. Сыйфатларның чагыштыру дәрәҗәсе | Татарстан табигатен сурәтли, анда яшәүче җәнлекләрне атый, нинди агачлар үскәнен атый белү | күл, чишмә, нарат, чыршы, каен, имән, поши, тиен, кабан дуңгызы |
| 48–49 | Сыйфатларның артыклык дәрәҗәсе. Татарстан елгалары | Татарстан елгаларын атый белү | |
| 50–51 | Кабатлау дәресләре | | |
| **Хайваннар һәм кошлар дөньясында. (13 сәгать)<br>III Мир вокруг меня** | | | |
| 52–53 | Кошлар — безнең дусларыбыз. Исемнәрнең килеш белән төрләнеше | Кышлаучы һәм күчмә кошларны әйтә белү | кышлаучы, күчмә |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 54–58 | Г. Лотфи. «Песнәк белән Әнисә» | «Песнәк белән Әнисә» эчтәлеге буенча сөйләшү; геройга бәя бирү | |
| 59–60 | Кошларга җимлек | Кошларны яратуың турында әйтә белү. Җимлек ясавың, аны кая куйганың турында әйтә, дустыңнан сорый белү | җимлек |
| 61–62 | Йорт һәм кыргый хайваннар. Зоопаркта | Йорт, кыргый хайваннарның исемнәрен атый, аларны сурәтли белү | йорт хайваннары, кыргый хайваннар |
| 63–64 | Кабатлау дәресләре | | |
| **Сәламәтлек — зур байлык. (16 сәгать)**<br>**I Мир моего «Я»** | | | |
| 65–66 | Тән әгъзалары атамалары | Кайсы җирең авыртуы/авыртмавы турында хәбәр итә белү.<br>Табибка кайсы җирең авыртуын әйтә белү | Кай җирең авырта? |
| 67 | Кышкы һәм җәйге спорт төрләре | Кышкы һәм җәйге спорт төрләрен әйтә белү | |
| 68–69 | «Дуслар» хикәясе | Чаңгы ярышына барганыңны, катнашканыңны әйтә белү | |
| 70–71 | «Дуслар» хикәясен иң яхшы сөйләүчегә конкурс | Хикәянең эчтәлеген сөйли белү; геройларга бәя бирү | |
| 72–74 | Билгесез үткән заман хикәя фигыльнең III зат берлек сан формасы.<br>А. Алишның «Куян кызы» әкияте | Билгесез үткән заман хикәя фигыль формасын сөйләмдә куллана белү | |
| 75–77 | Без сәхнәдә уйныйбыз | Әкиятне сәхнәләштерә белү | |
| 78–79 | Шугалакта.<br>«Бүген ял көне» тексты | Тимераякта шуа белгәнеңне/белмәгәнеңне әйтә белү | |
| 80 | Кабатлау дәресе | | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| **Минем дусларым. (6 сәгать)**<br>**III Мир вокруг меня** | | | |
| 81–83 | Исемнәрнең тартым белән төрләнеше. «Минем дустым» | Дустыңның барлыгын, юклыгын, исемен яшен сорый, әйтә белү. Схема буенча дустың турында сөйли белү | |
| 84–86 | Сүз ясагыч кушымчалар: *-чы/-че.* Әти-әниләрнең һөнәрләре. И. Туктарның «Алма» хикәясе | -чы/-че кушымчасы ярдәмендә яңа сүзләр ясалу | һөнәр исемнәре |
| **Безнең шөгыльләр. (5 сәгать)**<br>**III Мир вокруг меня** | | | |
| 87–88 | Җәйге һәм кышкы уен төрләре турында сөйләшү | Шөгыльләрнең исемнәрен әйтә белү; бер-береңне уеннарга чакыру | |
| 89–91 | «Минем дустым» хикәясе | Дустың белән бергә нинди шөгыльләрдә катнашуың турында сөйләшү | |
| **Минем бер көнем. (7 сәгать)**<br>**I Мир моего «Я»** | | | |
| 92–93 | Сәгать ничә? Көндәлек режим. *Аннан соң* вакыт рәвеше | Җәйге һәм кышкы уен төрләрре | |
| 94–95 | М.Җәлил. «Сәгать» | Шигырьне сәнгатьле уку; үзеңнең көндәлек режимың турында сөйли белү; геройга бәя бирү | |
| 96–98 | Бәйлек сүзләр. И.Туктар. «Авыраяк» хикәясе | Бәйлек сүзләрне сөйләмдә куллана белү | |
| **Без сәяхәт итәбез. (4 сәгать)** | | | |
| 99 | Без сәяхәт итәбез | Җәй көне кая барганыңны, нәрсә белән барганыңны, ничек ял иткәнеңне сөйли белү | |
| 100–101 | Бари Рәхмәт. «Минем дуслар» шигыре | «Минем дуслар» шигырен сәнгатьле укый белү | |
| 102 | Кабатлау дәресләре | | |

**4 нче сыйныфта укучы рус телле балаларның татар теле буенча белем дәрәҗәләрен билгеләү үрнәкләре**

**Яңа уку елы котлы булсын!**

**1. Переведи.**

Пример — упражнение —
задача — вопрос —
успехи — ответ —

**2. Составь словосочетания, подбирая слова из двух колонок.**

мисал
мәсьәлә
контроль эш
җавап
сорау
күнегү
диктант



чиштем
бирдем
яздым
әйттем
эшләдем

**3. Переведи вопросы, составь 3–4 предложения.**

Кто? Что? Какой? Что делает? Как? Когда? Откуда? Где?

**4. Скажи о том:**

— сколько тебе лет;
— в какой школе ты учишься;
— в каком ряду ты сидишь;
— сколько мальчиков и девочек в классе;
— сколько человек у вас в семье.

**5. Какие вопросы задашь, чтобы получить такие ответы?**

— ... ?
— Юк, без диктант яздык.
— ... ?
— Мин «дүртле» алдым.
— ... ?
— Ике хәрефне дөрес язмаганмын һәм бер өтерем юк.
— ... ?
— Юк, урамга чыкмыйм, мин дәрес әзерлим.

**6. Сообщи о том, что у тебя нет тетради, линейки, карандаша. Попроси их у друга.**

**7. По вопросам составь рассказ на тему «Мин мәктәптә».**
1) Син ничәнче мәктәптә укыйсың?
2) Син ничәнче сыйныфта укыйсың?
3) Сыйныфта ничә малай, ничә кыз?
4) Син дәрестә нишлисең?
5) Син нинди билгеләр аласың?

**Минем туган илем**

**1. Запиши названия рек по-татарски.**
Волга — ... , Белая — ... , Ик — ... , Кама — ... , Вятка — ... .

**2. Запиши названия городов по-татарски.**

Казань —
Зеленодольск —
Чистополь —
Альметьевск —
Елабуга —
Мензелинск —
Заинск —
Нижнекамск —
Буинск —
Набережные Челны —

**3. Запиши перевод словосочетаний.**
Наша республика, ваш город, наша столица, наш язык, наши праздники, ваши имена.

**4. Как скажешь, что вы:**
— летом идёте в поход;
— любите природу?

**5. Спроси друга:**
— какие реки есть в Татарстане;
— какие животные обитают в Татарстане?

## Туган як табигате

**1. Переведи.**

Трава —
растение —
природа —
дерево —
куст —
лекарственные травы —

**2. Вставь вместо точек подходящие по смыслу слова.**

Җылы ..., салкын ..., сары ..., кыска ..., озын ..., болытлы ... .

**3. Продолжи предложения:**

1) Дару үләннәре безгә кирәк, чөнки ...
2) Дару үләннәре файдалы, шуңа күрә ... .

**4. Какие вопросы задашь, чтобы получить такие ответы?**

— ... ?
— Без урманда, болында булдык.
— ... ?
— Дару үләннәре җыйдык.
— ... ?
— Әйе, күп җыйдык.
— ... ?
— Мәтрүшкә җыйдык.

**5. Дополни диалог.**

— … ?
— Әйе, мин куян күрдем.
— ... ?
— Урманда.
— ... ?
— Җәй көне.
— Куян нинди төстә иде?
— ... .

**6. Какие вопросы задашь, чтобы узнать:**

— злой ли медведь;
— маленький ли ёжик;

— хитрая ли лиса;
— пугливый ли заяц?

**Хайваннар һәм кошлар дөньясында**

**1. Переведи.**

Птица, дикое животное, живёт, зимующий, перелётный, в тёплые края, летает, плавает, кормушка.

**2. Спроси у друга:**

— какие птицы зимуют у нас;
— какие птицы улетают в тёплые края;
— какие животные обитают (живут) в Татарстане.

**3. Опишите животные.**

— Куян — куркак, соры, озын колаклы, сикерә.
— Бүре — ...
— Төлке — ...
— Тиен — ...
— Песнәк — ...
— Балык — ...

**4. Дополни диалог.**

— ... ?
— Мин җимлеккә ипи куйдым.
— Нинди кошлар килделәр?
— …

**Сәламәтлек — зур байлык**

**1. Напиши названия частей тела.**

**2. Как скажешь о том, что:**

— ты заболел;
— у тебя болит рука (зуб, нога, палец, ухо);
— тебе нужно лекарство?

**3. Поинтересуйся у друга:**

— что у него болит;

— болит ли у него рука (зуб, нога, палец, ухо);
— надо ли ему лекарство.

**4. Посоветуй другу:**
— всегда слушаться маму;
— в холодные дни одеваться тепло;
— пойти к доктору.

**5. Как скажешь, что:**
— зимой ты катаешься на лыжах (коньках);
— летом ездишь (катаешься) на велосипеде (роликах);
— купаешься на речке;
— ходите с друзьями на стадион?

**6. Дополни диалог.**
— ... ?
— Мин егылдым.
— ... ?
— Минем аягым авырта.

## Минем дусларым

**1. Вместо точек поставь нужные слова.**
Минем исемем, дустым.
Синең … , ... .
Аның ... , ... .

**2. Подбери антонимы.**

| | | |
|---|---|---|
| эшчән | ? | куркак |
| яхшы | | ялкау |
| батыр | | саран |
| юмарт | | начар |

**3. Узнай у друга:**
— есть ли у него санки, лыжи, коньки;
— идёт ли он сегодня играть в хоккей;
— есть ли у них во дворе каток;
— идёт ли он вечером в кружок.

**4. Пригласи друга:**
— кататься на лыжах (санках, коньках);
— играть на улице;
— к себе в гости.

**5. По данным вопросам напиши рассказ о близком друге.**
1) Синең дустың бармы?
2) Аның исеме ничек? Аңа ничә яшь?
3) Дустың кайда яши?
4) Ул кайда һәм ничек укый?
5) Сез бергә нишлисез?

## Безнең шөгыльләр

**1. Узнай у друга:**
— любит ли он читать;
— умеет ли он плавать;
— нравится ли ему петь, танцевать.

**2. Предложи другу:**
— поиграть в шахматы;
— записаться на бокс;
— покататься на велосипеде.

**3. Дополни диалог.**
— ... ?
— Әйе, минем дустым бар.
— Сез бергә нишлисез?
— ... .

**4. Составь по вопросам рассказ о своем увлечении.**
— Сиңа нинди шөгыльләр ошый?
— Син анда ничә ел йөрисең?
— Сез анда нишлисез?

## Минем бер көнем

**1. Спроси у друга, во сколько часов он:**
— встаёт;
— идёт в школу;
— делает уроки;
— помогает маме;
— играет на улице?

**2. Дополни диалог.**
— ... ?
— Мин сәгать җидедә торам.
— ... ?
— Әйе, мин иртән зарядка ясыйм.
— ... ?
— Мәктәпкә дустым белән барам.

**3. Составь рассказ о своём режиме дня.**

## Без сәяхәт итәбез

**1. Скажи о том, что:**
— ты любишь путешествовать;
— вы были в Москве (Санкт-Петербурге);
— вы путешествовали на теплоходе.

**2. Спроси друга:**
— куда он поедет летом;
— был ли он на море;
— любит ли он путешествовать?

**3. Составь небольшой рассказ о Татарстане.**

# ЭЧТӘЛЕК

4 нче сыйныфта «Татар теле» укыту-методик комплекты белән эшләү үзенчәлекләре ........ 2

Ишетеп аңлау күнегүләре ........ 5

Федераль эш программасына нигезләнгән календарь-тематик план ....... 24

4 нче сыйныфта укучы рус телле балаларның татар теле буенча белем дәрәҗәләрен билгеләү үрнәкләре ........ 29

*Методическое пособие*

**Хайдарова** Роза Закиевна
**Галиева** Наиля Галиевна

Книга для учителей к учебнику «Татар теле. 4 класс»

4 класс

Редактор:
**Ильгизар Закиев**

Компьютерная вёрстка
**Елены Шараповой**

Подписано в печать 20.08.2024.
Формат 170x205 1/4. Бумага офсетная.
Гарнитура «Arial». Тираж экз. Заказ №

Издательство «Татармультфильм»
420066, г. Казань, пер. Односторонки Гривки, д. 32, помещ. 2

Отпечатано в полном соответствии с качеством
предоставленных материалов в типографии



9 785906 508508

«Татармультфильм»